КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 декабрь

г.Казань

№ 1152

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 май, 321 нче; 2016 ел, 9 июль, 465 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 610 нчы; 2017 ел, 24 август, 598 нче; 2018 ел, 11 апрель, 447 нче, 2019 ел, 12 апрель, 280 нче; 2021 ел, 28 апрель, 288 нче; 2021 ел, 3 август, 676 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.»;

2.8 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия биргәндә:

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – ярдәм күрсәтелүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, кимендә 65 берәмлек;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – ярдәм күрсәтелүче үзмәшгуль гражданнар саны, кимендә 25 берәмлек;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелгән хезмәтләр саны, кимендә 12 930 берәмлек;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда –экспортка ярдәм күрсәтү үзәге хезмәтләре күрсәтелгәне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, кимендә 20 берәмлек;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – ярдәм күрсәтелүче, шул исәптән уку программаларын үткән үзмәшгуль гражданнар саны, кимендә 1000 берәмлек;

б) әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының алтынчы абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – чараларны тормышка ашыруга җәлеп ителгән затлар саны, кимендә 1 230 кеше һәм (яки) онлайн һәм офлайн массакүләм мәгълүмат чараларына чыгу (аларда публикацияләр) саны – кимендә 620 берәмлек.

Әлеге пунктчада күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү срогы – субсидия бирү елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча.»;

2.7 пунктның тугызынчы абзацында «ирешү турындагы хисап» сүзләре алдына «күрсәткечләргә» сүзләрен өстәргә;

2.10 пунктның «а» пунктчасындагы өченче абзацында «ирешү турындагы хисап» сүзләре алдына «күрсәткечләргә» сүзләрен өстәргә;

2.10 пунктның «б» пунктчасындагы икенче абзацында «ирешү турындагы хисап» сүзләре алдына «күрсәткечләргә» сүзләрен өстәргә;

2.12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.»;

2.13 пунктның дүртенче абзацында «ирешү турындагы хисап» сүзләре алдына «күрсәткечләргә» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар (2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның уналтынчы һәм унҗиденче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин